**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2025елның «17» декабре 2395 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан муниципаль сатып алуларны гамәлгә ашыру һәм килештерү тәртибен раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген арттыру, сатып алуларны тормышка ашыруның үтә күренмәлелеген һәм ачыклыгын тәэмин итү, шулай ук Лаеш муниципаль районында муниципаль сатып алулар системасын камилләштерү максатларында карар бирәм:

1. Лаеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре 20,0 мең сумлык товар сатып алулар башкарганда bp.zakazrf.ru сатып алу модулен кулланырга яисә сатып алуларны федераль законның 05.04.2013 № 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 маддәсенең 12 өлеше нигезендә башкарырга тиеш, дип билгеләргә..

2. 200,0 мең сумлык эшләр һәм хезмәтләр сатып алуларны башкарганда Лаеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча конкурент ысулларны 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кулланырга тиеш дип билгеләргә.

3. Лаеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарның таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары Л.М. Җамалиевка йөкләргә.

6. Әлеге карар 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкче Р.Т. Гарифуллин